ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Молодежная, д.13, д. Средняя
Корса, Арский муниципальный район,
422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яшьләр ур, 13 нче йорт, Урта Курса
авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**«18» июль 2016 ел** **№ 11**

**Урта Курса авыл җирлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында.**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карарына таянып, “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында” башкарма комитет карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең түбәндәге административ регламентларын расларга:

1.1. Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль милектәге торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1нче кушымта).

1.2. Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. Документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта).

1.4. Васыятьләр һәм ышанычнамәләр таныклыгы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта).

1.5. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта).

1.6. Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буенча уза торган маршрутлар буенча авыр йөкләр, зур габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (7 нче кушымта).

2. “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 2013 елның 04 июнендәге 7 номерлы Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитеты карарын(04.11.2015, № 13 үзгәреш белән) үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ОГРН 1061685004732 * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «СРЕДНЕКОРСИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» * ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СРЕДНЕКОРСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609009731